**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

# КАРАР

«14» декабрь 2018ел | Яр Чаллы | № 6092

2019 елга Тукай муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Федераль законның 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2013 елның 30 декабрендәге 1096 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары һәм Тукай муниципаль районы Уставы нигезендә,

**КАРАР**

1. 2019 елга кушымта итеп бирелә торган түбәндә күрсәтелгәннәрне расларга:
Тукай муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карап тоту һәм карау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар, №1 кушымта нигезендә;
Тукай муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны карап йөргән һәм караган өчен ата-аналарга түләү күләме, №2 кушымта нигезендә.
2. Тукай муниципаль районының финанс-бюджет палатасын әлеге карарның 1 пункты белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен финанслау нормативлары нигезендә мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең мәгариф мәсьәләләре буенча урынбасары А.Х. Мөхәммәтҗановага йөкләргә.

Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Г. Авзалов